| СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

12.12.2019 Баулы шәһәре № 237

Баулы муниципаль районының
2020 елга һәм 2021-2022 еллар
план чорына социаль-икътисадый
үсешенең төп күрсәткечләре
фаразы турында

Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш буенча урынбасары Э. И. Галимовның “Баулы муниципаль районының 2020 елга һәм 2021-2022 еллар план чорына социаль-икътисадый үсешенең төп күрсәткечләре фаразы турында” докладын тыңлаганнан һәм тикшергәннән соң Баулы муниципаль районы Советы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты, шәһәр хезмәтләре тарафыннан төрле милек формасындагы предприятиеләр белән берлектә 2019 елда районның социаль-икътисади үсешен тәэмин итү буенча билгеле бер эш башкарылуын билгеләп үтә.

Баулы муниципаль районының 2019 елгы социаль-икътисадый үсешенең төп параметрларын анализлау түбәндәге бәяләү нәтиҗәләрен күрсәтте:

- тулай территориаль продукт 43,5 млрд. сум тәшкил итәчәк;
- төп капиталга инвестицияләр - 4,3 млрд. сум;
- авыл хуҗалыгы продукциясе күләме - 3,2 млрд. сум;
- 2019 елда җитештерелгән һәм төяп җибәрелгән продукция, эшләр һәм хезмәтләр күләме 9,4 млрд. сум тәшкил итәчәк.

Шәһәр һәм район предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре халыкка 712 млн. сумлык түләүле хезмәт күрсәтәчәк. Ваклап сату товар әйләнеше 4,4 млрд. сум тәшкил итәчәк.

Баулы муниципаль районының 2019 елдагы үсеш тенденцияләреннән чыгып, Баулы муниципаль районының 2019 елга һәм 2021-2022 еллар план чорына социаль-икътисади үсеш фаразы формалаштырылды.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә, Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2019 елгы социаль-икътисадый үсешнең башлангыч йомгаклары турында мәгълүматны игътибарга алырга (1нче кушымта).

2. Баулы муниципаль районының 2020 елга һәм 2021-2022 еллар план чорына социаль-икътисадый үсешенең төп параметрларын расларга (2нче кушымта).

3. Барлык милек формасындагы сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

- 2020 елга һәм 2021-2022 еллар план чорына социаль-икътисадый үсешнең төп күрсәткечләрен үтәүне тәэмин итәргә;

- эшчәнлекне җитештерү куәтләрен нәтиҗәле файдалануга, хезмәт шартларын яхшыртуга һәм эшләүчеләрнең сәламәтлеген саклауга, хезмәт хакын вакытында түләүгә юнәлдерергә, эш урыннарын кыскартуга юл куймаска;

- хезмәт хакын арттыру буенча чаралар күрергә һәм аның дәрәҗәсен минималь куллану бюджеты күләменнән түбәнрәк төшерүгә юл куймаска.

4. Баулы муниципаль районы башкарма комитетына:

- тырышлыкны халыкның тормыш сыйфатын күтәрүгә юнәлдереп, муниципаль районның комплекслы социаль-икътисади үсешен тәэмин итүгә;

- булган мөмкинлекләр һәм икътисади үсеш перспективалары кысаларында бюджет чeлтәрен оптимальләштерү, энергияне саклау һәм энергия сыйдырышлылыгын киметү, социаль өлкә, торак-коммуналь хуҗалык тармакларында бюджеттан тыш юнәлешләрне үстерү буенча чаралар күрергә.

5. Әлеге карарны «Интернет» челтәрендәге Баулы муниципаль районы сайтында (http://bavly.tatarstan.ru) һәм http://pravo.tatarstan.ru сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Советының икътисади үсеш, эшмәкәрлек, кече бизнес һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башлыгы, район Советы Рәисе Р.Х. Гатиятуллин

Баулы район Советының
2019 елның 12 декабрендәге
237 номерлы карарына
1нче кушымта

Баулы муниципаль районының 2019 елның узган чорындагы социаль-икътисадый үсеше нәтиҗәләре һәм Баулы муниципаль районының 2019 елдагы социаль-икътисадый үсеше буенча көтелгән нәтиҗәләр

| Күрсәткечләр | 2019 гыйнвар-июнь | 2019 бәя |
|---|---|---|
| I. Макроикътисади күрсәткечләре | | |
| 1. Тулай төбәк продукты (төп бәяләрдә), млн. сум. | 21753,4* | 43506,8 |
| 2. Төяп озатылган продукция күләме (эшләр, хезмәтләр күрсәтү), млн. сум. | 4758,7 | 9372,9 |
| 3. Сәнәгать җитештерүе индексы, алдагы елга % | 104,5 | 102,0 |
| 4. Авыл хуҗалыгы продукциясе күләме, млн. сум. | - | 3207,1 |
| 5. Барлык финанслау чыганаклары хисабына территория буенча инвестицияләр күләме (төп капиталга) млн. сум. | 1818,3 | 4297,4 |
| 6. Финанслауның барлык чыганаклары хисабына торак йортларны файдалануга тапшыру, мең кв. м. | 6,9 | 12,0 |
| 7. Ваклап сату әйләнеше, млн. сум. | 2136,9 | 4396,8 |
| 8. Хезмәт хакы фонды, млн. сум. | 1597,0 | 3065,6 |
| 9. Теркәлгән эшсезләр саны (чор ахырына) мең кеше | 0,14 | 0,13 |
| 10. Икътисади актив халыкның гомуми санында эшсезләр өлеше, % | 0,79 | 0,71 |
| II. Тормыш дәрәҗәсе | | |
| 1. Җан башына уртача айлык керем, сум | 25916,4 | 28870,1 |
| узган елга карата % | 111,9 | 103,6 |
| 2. Уртача айлык хезмәт хакы (бер елга уртача). | 32533,6 | 33746,8 |
| узган елга карата % | 103,3 | 102,8 |
| II. Сәнәгать | | |
| Сәнәгать продукциясенең мөһим төрләрен җитештерү: | | |
| Нефть, млн. т. | 1,2 | - |
| III. Агросәнәгать комплексы | | |
| 1. Авыл хуҗалыгы продукциясенең төп төрләрен җитештерү: | | |
| Ашлык (эшләп бетергәннән соң), мең т. | - | 74,9 |
| Ит (терлек һәм кош ите), мең т. | 0,8 | 1,5 |
| Сөт, мең т. | 7,8 | 15,8 |
| IV. Кулланучылар базары | | |

| Күрсәткечләр | 2019 гыйнвар-июнь | 2019 бәя |
|---|---|---|
| 1. Җәмәгать туклануы әйләнеше, млн. сум. | 101,1 | 204,4 |
| 2. Халыкка түләүле хезмәтләр күләме, млн. сум. | 368,7 | 712,4 |

Баулы муниципаль район Советының
2019 елның 12 декабрендәге
237 номерлы карарына
2нче кушымта

# Баулы муниципаль районының 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына социаль-икътисадый үсеш ФАРАЗЫ

| Күрсәткечләр | 2020 фараз | 2021 фараз | 2022 фараз |
|---|---|---|---|
| I. Макроикътисади күрсәткечләр | | | |
| 1. Тулай төбәк продукты (төп бәяләрдә), млн. сум. | 45595,1 | 48741,2 | 52153,1 |
| 2. Төяп озатылган продукция күләме (эшләр, хезмәтләр күрсәтү), млн. сум. | 9944,7 | 10630,9 | 11385,6 |
| 3. Сәнәгать җитештерүе индексы, алдагы елга % | 102,5 | 103,0 | 103,0 |
| 4. Авыл хуҗалыгы продукциясе күләме, млн. сум. | 3209,2 | 3212,2 | 3215,1 |
| 5. Барлык финанслау чыганаклары хисабына территория буенча инвестицияләр күләме (төп капиталга) млн. сум. | 4387,6 | 4492,9 | 4627,7 |
| 6. Финанслауның барлык чыганаклары хисабына торак йортларны файдалануга тапшыру, мең кв. м. | 12,0 | 12,0 | 12,0 |
| 7. Ваклап сату әйләнеше, млн. сум. | 4572,7 | 4783,0 | 5031,7 |
| 8. Хезмәт хакы фонды, млн. сум. | 3094,4 | 3183,8 | 3302,4 |
| 9. Теркәлгән эшсезләр саны (чор ахырына) мең кеше | 0,13 | 0,13 | 0,13 |
| 10. Икътисади актив халыкның гомуми санында эшсезләр өлеше, % | 0,71 | 0,71 | 0,71 |
| II. Тормыш дәрәҗәсе | | | |
| 1. Җан башына уртача айлык керем, сум | 29909,4 | 31105,8 | 32412,2 |
| узган елга карата % | 103,8 | 104,0 | 104,2 |
| 2. Уртача айлык хезмәт хакы (бер елга уртача). | 34520,0 | 35612,5 | 37089,1 |
| узган елга карата %. | 102,3 | 103,2 | 104,1 |
| III. Агросәнәгать комплексы | | | |
| 1. Авыл хуҗалыгы продукциясенең төп төрләрен җитештерү: | | | |

| Күрсәткечләр | 2020 фараз | 2021 фараз | 2022 фараз |
|---|---|---|---|
| Ашлык (эшләп бетергәннән соң), мең т. | 75,0 | 75,4 | 75,6 |
| Ит (терлек һәм кош ите), мең т. | 1,6 | 1,7 | 1,8 |
| Сөт, мең т. | 16,5 | 17,0 | 17,8 |
| IV. Кулланучылар базары | | | |
| 1. Җәмәгать туклануы әйләнеше, млн. сум. | 204,9 | 205,2 | 205,9 |
| 2. Халыкка түләүле хезмәтләр күләме, млн. сум. | 733,0 | 758,7 | 790,5 |